| | | |
|---|---|---|
| **СОВЕТ СТАРОМАТВЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ МАТВЕЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

РЕШЕНИЕ с. Старая Матвеевка КАРАР

№ __1__ 16.09.2019

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы "Иске Матвеевка авыл жирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында"гы Карары турында

О внесении изменений в Устав муниципального образования «Староматвеевское сельское поселение» Мензелинского муниципального района Республики Татарстан

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы "Иске Матвеевка авыл жирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасының 2018 елның 16 мартындагы "Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үиздарә турында"гы №45-ЗРТ" Законына үзгәрешләр кертү турындагы №10-ЗРТ Законы нигезендә, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл жирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы "Иске Матвеевка авыл жирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертергә:

1.1 "Ачык тыңлаулар" 19 маддәсенең 2 башлыгы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле әһәмияттәге мәьәләләр буенча муниципаль норматив-хокукый актлар проектларын тикшерү өчен Җирлектә яшәүчеләр, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы, Җирлек Башкарма комитеты катнашында ачык тыңлаулар уздырылырга мөмкин".

1.2 "Ачык тыңлаулар" 19 маддәсенең 2 башлыгы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Ачык тыңлаулар халык яисә Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы, җирлек Башкарма комитеты инициативасы буенча уздырыла.

Халык яисә Җирлек Советы инициативасы буенча уздырыла торган ачык тыңлаулар Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә, Җирлек Башлыгы инициативасы буенча – Җирлек Башлыгы, ә Җирлек Башкарма комитеты инициативасы буенча – Җирлек Башкарма комитеты”.

1.3 «Гражданнар җыены” 22 маддәсенең 2 башлыгы, 10 пунктнын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

10) яңадан барлыкка килгән җирлек булдыру турында халык инициативасын тәкъдим итү максатларында, шулай ук сайлау хокукына ия булган халык саны 300 дән күбрәк булса, яңадан барлыкка килгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләләре буенча авыл арасындагы территориядә урнашкан торак пунктта;

1.4 29 маддәсенең 3 башлыгы түбәндәге эчтәлектәге 3 пункт белән тулыландырырга:

«п.3.Җирлек халкы санының артуы яисә кимүе белән бәйле рәвештә Җирлек Советы депутатлары санын арттыручы яисә киметүче үзгәрешләр күрсәтелгән үзгәрешләрне кертү турындагы муниципаль норматив хокукый актны кабул иткән Җирлек Советы вәкаләтләре чыгу белән көченә керә”.

2. Гамәлдәге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә җибәрергә.

3. Гамәлдәге карар 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ Федераль законының 44 маддәсендә каралган тәртиптә көченә керә.

ТР Минзәлә муниципаль районының
Иске Матвеевка авыл җирлеге
Башлыгы: А.Х.Нуриев